| ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ<br>СПАССКОГО<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>СПАС<br>МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ<br>БАШКАРМА КОМИТЕТЫ |
|---|---|

ПОСТАНОВЛЕНИЕ
№ 307

КАРАР
12.05 2021 ел

Торак урыны мәйданының хисап нормасы һәм социаль наем шартнамәсе буенча торак урыны мәйданын бирү нормасы турында

Россия Федерациясе Торак кодексының 50, 58 статьяларын гамәлгә ашыру максатларында, Татарстан Республикасы Спас муниципаль районы Башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Спас муниципаль районында торак урыны мәйданының исәпкә алу нормасын билгеләргә, шуннан чыгып, гражданнарның торак урыннарына мохтаҗлар буларак исәпкә алу максатларында торак урынының гомуми мәйданы белән тәэмин ителеше дәрәҗәсе гаиләнең бер әгъзасына 12 кв.метрдан да ким булмаган күләмдә билгеләнә.

2. Социаль наем шартнамәсе буенча торак урын мәйданын социаль наем шартнамәләре буенча бирелә торган торак урыннар белән тәэмин ителешнең ирешелгән дәрәҗәсеннән чыгып, Татарстан Республикасы Спас муниципаль районында бер гражданга торак урынның гомуми мәйданының 18 кв. метр күләмендә бирү нормасын билгеләргә.

3. Торак урынының гомуми мәйданын бирү нормасын арттыру Россия Федерациясе Торак кодексында каралган очракларда рөхсәт ителә.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Спас муниципаль районының рәсми сайтында, хокукый мәгълүматның рәсми сайтында урнаштырырга (//http:pravo.tatarstan.ru).

5. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үземдә калдырам.

ТР Спас муниципаль районы
Башкарма комитеты җитәкчесе В.А. Осокин